**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ

14 август 2023 ел.

КАРАР

№ 189

Әтнә район Советы “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 №414-ФЗ Федераль законына нигезләнеп Татарстан Республикасы Әтнә район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы" Әтнә район Советының 20.04.2021 елгы 46 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертү:

Нигезләмәнең 2 бүлегенең 8 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты каршында» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршында»дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе Г. Г. Хәкимов